**Татарстан Республикасы**
**Аксубай муниципаль районы Иске Кармәт авыл җирлеге Советы**

**Карар**

**№ 16** **«18» январь 2016 ел**

**Иске Кармәт авыл җирлеге Советы башлыгының 2015 елда авыл җирлегенең социаль – икътисадый үсеше нәтиҗәләре һәм 2016 елга фараз турында хисабы**

Иске Кармәт авыл җирлеге Советы башлыгының социаль нәтиҗәләр буенча хисабын тыңлап һәм фикер алышып – 2015 елда җирлекнең икътисади үсеше һәм 2016 елга фараз турында авыл җирлеге Советы 2015 елда җирлек халкы мәнфәгатьләрендә, «РФда җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Россия Федерациясенең 6.10.2003 елдагы 131-ФЗ номерлы Законы һәм 28.07.2004 елдагы 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, җирлек халкы мәнфәгатьләрендә эшләр башкарылган дип саный Татарстан Республикасында җирле үзидарә, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Кармәт авыл җирлеге Советы:

1 Иске Кармәт авыл җирлеге Советы башлыгы Мусабиков Фәнис Заяновичның 2015 елда авыл җирлегенең социаль – икътисадый үсеше нәтиҗәләре һәм 2016 елга фараз турында хисабын игътибарга алырга.

2. 2016 елда авыл җирлеген социаль – икътисади үстерүнең төп бурычы булып халыкның тормыш сыйфаты үсешен тәэмин итү санала.

3. Шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерүгә аерым игътибар бирергә.

4. Кредитлау һәм торак төзелеше өлкәсендә гамәлгә ашырыла торган программаларның мөмкинлекләрен авылда яшьләрне ныгыту өчен максималь файдалану.

5. Халыкның тормыш дәрәҗәсен төшерүгә юл куймау һәм гражданнарның социаль хезмәтләргә тигез керү мөмкинлеген тәэмин итү буенча чаралар күрергә.

6. Хокук саклау органнары белән берлектә җәмәгать иминлеге дәрәҗәсен күтәрү һәм җәмәгать тәртибен, гражданнарның тормышын һәм сәламәтлеген һәм дәрәҗәсен ышанычлырак яклауны тәэмин итү буенча алга таба эш алып барырга.

7. Торак пунктларны төзекләндерү, яшелләндерү һәм чистарту, экологик куркынычсызлыкны тәэмин итү буенча чараларны дәвам итәргә.

8. Авыл җирлеге башкарма комитетына хисап докладында һәм аны тикшергәндә әйтелгән искәрмәләрне һәм тәкъдимнәрне үтәү буенча чаралар планын эшләргә тәкъдим итәргә.

9. Авыл җирлеге Советы аппаратына хисап докладында һәм аны тикшергәндә әйтелгән тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне гомумиләштерергә.

10. Әлеге карарны Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга http:aksubaevo.tatarstan.ru.

11. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Иске Кармәт авыл җирлеге Советының даими комиссияләренә йөкләргә.

Иске Кармәт авыл җирлеге
Советы Рәисе: Ф.З.Мусабиков